РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Карамалинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 8, Азнакаевский район,
с.Карамалы, 423301,
тел./факс (885592)45-6-42
E-mail: Karam.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Карамалы авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 8нче йорт, Азнакай районы,
Карамалы авылы, 423301
тел./факс (885592)45-6-42
E-mail: Karam.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«12» ноябрь 2024 ел** **№ 7**

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Таллы-Бүләк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1. Таллы-Бүләк авылы теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Таллы-Бүләк торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының 2024 елның 22 ноябрендэ 10.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, махсус хәрби операциягә җибәрелгән мобилизацияләнгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге Таллы-Бүләк торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм

транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру

- Таллы Бүләк торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау; (лампалар, энергияне саклый торган яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү)
- җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру.
- Таллы Бүләк авылында торак пункт территориясен төзекләндерү; (юлларны кардан чистарту, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).
- Ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;
- Таллы Бүләк торак пунктында ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү; (агачларны кисү, куакларны кисү, үләнне чаптыру, чүп-чарны җыю, төзелеш материаллары сатып алу)

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Карамалы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык А.Р. Ногманов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАРАМАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАМАЛИНСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЗНАКАЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН